Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Урман- Кәләй авыл җирлегенең
Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе гражданнар җыены нәтиҗәләре
турындагы карары

31 октябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2025 елның 31 октябрендә 08 сәгать 00 минутта булган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге: «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авыл җирлеге Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 3500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (скважинаны төзекләндерү һәм тоташтыру, скважинаны тоташтыру һәм бәйләү өчен кирәкле материаллар сатып алу) тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, торак пункт чикләрендәге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын урнаштыру, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу/юлларга асфальт салу, асфальт юллардагы чокырларны ремонтлау, юлларга вак таш салу)?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 14 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 10 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 10 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Кәләй авыл җирлегенең Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Кәләй авыл җирлеге Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 3500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (скважинаны төзекләндерү һәм тоташтыру, скважинаны тоташтыру һәм бәйләү өчен кирәкле материаллар сатып алу) тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, урнаштыру , ремонтлау, тоту торак пункт чикләрендәге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары (вак таш сатып алу/юлларга асфальт салу, асфальт юлларга чокырларны ремонтлау, юлларга вак таш салу)?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе , Железнодорожная урамы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Кәләй авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Урман- Кәләй авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Фәләхиев